Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы

Иске Тимошкино авыл җирлеге Советы

КАРАР

№28 23.09. 2016 ел

Җирле референдум үткәрү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьяларына, Татарстан Республикасы Законының 18 статьясына ярашлы 24.04.2004 № 23-ТРЗ «Җирле референдум турында», Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы «Иске Тимошкино авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Тимошкино авыл жирлеге Советы:

1.Җирле референдум үткәрү инициативасы:

"Сез 2017 елда Старотимошкино авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә ризамы, 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча жирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп:

1. Торак пункт чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне, су чыгаруны, халыкны ягулык белән тәэмин итүне Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә оештыру.

2. Ритуаль хезмәтләр һәм җирләү урыннарын тоту оештыру.

3. Торак пунктлар чикләрендә җирле әһәмияттәге юлларга карата юл эшчәнлеге.

4. Торак пункт чикләрендә янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү.

ӘЙЕ ЮК

2.Әлеге карарны Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга http://aksubaevo.tatar.ru Аксубай муниципаль районы Иске Тимошкино авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

ТР Аксубай муниципаль районы Иске Тимошкино авыл жирлеге Советы Рәисе: Ф.Н. Степанов